УДК 82'0

***Н.Р. Вахитов***

# ХӘЛИМ САБИТНЫҢ «АЛТАЙЛАРГА ТАБА» СӘЯХӘТНАМӘСЕНДӘ КАЗАН

В статье анализируется фрагмент «В Казани» из путевых заметок (сэяхэтнамэ) «К Алтаю» (1911) татарского интеллектуала и общественного деятеля Халима Сабита (1883–1946). Текст рассматривается как репрезентативный историко-литературный источник, позволяющий реконструировать динамику национального самосознания российских мусульман-татар в межреволюционный период (1905–1917). Автор конструирует образ Казани как «исторического палимпсеста», в котором героические образы эпохи Казанского ханства переплетаются с трагедией утраты независимости и социально-политическим кризисом начала XX века. Особое внимание уделено историософским взглядам Х. Сабита, основанным на циклическом восприятии истории и диалектике «отчаяния и надежды». В контексте трансформации исторической памяти исследуются причины кризиса ведущих образовательных институтов (медресе «Мухаммадия») в годы политической реакции и процесс формирования образа «нового поколения» в среде мусульманской интеллигенции.
**Ключевые слова:** Халим Сабит, Казань, сэяхэтнамэ, «Тюрк юрду», национальное самосознание, мусульмане-татары, историческая память, медресе «Мухаммадия», межреволюционный период

The article analyzes the fragment “In Kazan” from the travelogue (sayahatnama) “To the Altai” (1911) by the prominent Tatar intellectual and public figure Halim Sabit (1883–1946). The text is examined as a representative historical and literary source reflecting the dynamics of the national identity of Russia’s Muslim Tatars during the inter-revolutionary period (1905–1917). The author constructs the image of Kazan as a “historical palimpsest”, where the heroic images of the Kazan Khanate era intertwine with the tragedy of the loss of independence and the socio-political crisis of the early 20th century. Special attention is paid to Sabit’s historiosophical concept, based on a cyclical perception of history and the dialectic of “despair and hope”. Within the context of historical memory transformation, the study explores the causes behind the crisis of leading educational institutions (such as the Muhammadiya Madrasa) during the years of political reaction and the formation of the “new generation” image among the Muslim intelligentsia.
**Keywords:** Halim Sabit, Kazan, sayahatnama, “Türk yurdu”, national identity, Muslim Tatars, historical memory, Muhammadiya Madrasa, inter-revolutionary period

XX гасыр башы – татар халкы язмышына кискен үзгәрешләр алып килгән чор. Милли аң формалашу, мәгариф һәм мәдәният өлкәләрендә барган модернлашу хәрәкәте, милли интеллигенция, вакытлы матбугат ялару кебек фактлар – шуның дәлиле. Бу дәверне эчтән тоемлау, тирәнтен аңлау һәм күзаллау өчен иң беренче чыганаклар –

чор шаһитларының көндәлекләре, истәлекләре һәм юлъязмалары. Аларда заман сулышы, халыкның аң-зиһен кимәле, үткәнгә бәя бирү аркылы бүгенгене аңлау омтылышы, киләчәккә юнәлгән өметләр чагылыш таба.

Шундый кыйммәтле документлар рәтендә галим, җәмәгать хадиме, остаз һәм публицист Хәлим Сабитның (1883–1946) «Алтайларга таба» (1911) исемле зур күләмле сәяхәтнамәсе аерым урын биләп тора. Сембер губернасы Лабит авылында туып, Самара, Олы Тархан мәдрәсәләрендә укыган, соңрак атаклы «Хөсәения»дә сабак биргән, 1904 елда «милләтемә хезмәт дигән бөек идеал хакына», барын-югын фида итеп, ата-анасын, туганнарын, ватанын ташлап, олы михнәт-газапларга теш кысып, Истанбулга юл тоткан; башта Мәрҗән лицееен (1906), соңрак данлыклы дарелфөнүннең илаһият шөгъбәсен (1910) тәмамлаган зыялы мөгаллим 1911 елның җәендә Россия империясенең төрки кавемнәр гомер сөргән җирләре буйлап олы сәяхәткә кузгала. Берничә ай эчендә Одессадан башлап, Идел буе, Урал таулары, Себер һәм казак далаларын айкап йөри, Алтай тавы итәкләренә кадәр барып чыга, кайту юлында Уфа һәм Казан кебек мәркәзләрне зиярәт кыла; һәркайда халык белән очраша, аның йолалары, гореф-гадәтләре, яшәү рәвеше белән якыннан таныша, зыялылар, имамнар, милләт хадимнәре белән утырдаш була, мәктәп-мәдрәсәләр, мәчетләр, китапханәләр, җәмгыяте хәйрияләр эшчәнлегенә бәя бирә, ике инкыйлаб арасында (1905–1917) мәйданга чыккан милли-мәдәни җанлылык дәверендә халыкның тарихи хәтере һәм милли аңында барган үзгәрешләрне «читтән килгән» күзәтүче буларак кәгазь битләренә терки.

37 кисәктән торган сәяхәтнамәнең һәр бүлеге автор тукталган урыннар турында кыскача иҗтимагый-тарихи-этнографик очерк формасын ала. Сәяхәтнамә Йосыф Акчура мөдирлегендә чыккан «Төрек йорты» мәҗмугасында 1912–1917 еллар аралыгында басыла. Бу очеркларның иң кызыклыларыннан берсе – журналның 142 нче санында (30.08.1917) дөнья күргән «Казанда» бүлеге.

Дөньяга карашы традицион Шәрык-мөселман тарих белеме һәм «төрекчелек» идеологиясе катнашыннан хасил булган автор зиһенендә Казан шәһәре Русиядәге төрки кавемнәрнең символик башкаласы, сәяси мөстәкыйльлеген җуйса да, мәдәни һәм рухи әһәмиятен саклап калган изге кала булып күзаллана. Казанның топографиясен ул баштан ук бинар оппозициягә нигезләп карый. Бер якта мәчет-мәдрәсәләре, Печән базары, кабатланмас милли-мәдәни мохите белән «Татар бистәсе» урнашса, «Болак күперенең» аргы ягында «рус хәяты һәм хәрәкәте күзгә бәрелгән руслык дөньясы» яшәп килә. Бу күренешне автор үзе гомер иткән Истанбулның мөселман мәхәлләләре һәм христиан кварталларына (Бәйугълы) охшата. Татар-мөселман тормышының үзәге итеп Печән базары алына, ул «Казан мөселманнарының сәүдә мәркәзе, алыш-биреш итү, очрашып-күрешү, фикер алмашу урыны» дип атала.

Ләкин Казан тасвирламасының иң мөһим ягы – аның күпкатлы тарихи текстны хәтерләтүендә, хәзерге чынбарлык артында тарихи дәверләр авазы ишетелүдә. «Казанның җентекләп эшләнгән төпле язма тарихы булмаса да, шәһәргә барып чыккан яки аның исемен ишеткән төрек-мөселманның яше дә, карты да, укыганы да, укымаганы да күз уңында киң бер тарих сәхнәсе ачылганын күргән төсле була». Димәк, Казанда халыкның тарихи хәтере, иң самими хисләре, өмет-хыяллары, яшәү мәгънәсе гәүдәләнеш таба.

Шушы тарих сәхнәсендә үткәннәрнең ачысы да, төчесе дә йөгереп уза. Ханнар язмышы халык язмышына бәйләп карала, Казан тарихының фаҗигалы сәхифәләре тасвир кылына. «Тарихи яралар» сакральләштерелә, аеруча мулла Кол Шәрифнең, Сафа Гәрәй һәм Сахиб Гәрәй ханнарның, Сөембикә ханбикәнең «халык хәтерендәге» каһарман образлары торгызыла.

Хатирәләр галәменнән чынбарлыкка әйләнеп кайткан авторны каршылыклы хисләр биләп ала. Бу халәт: «Казанның үткәне, тарихы никадәр буталчык, никадәр табышмаклы булса, бүгенге хәле дә шул нисбәттә яшерен, серле булып кала бирә», – дигән сүзләр белән аңлатыла. Илдә барган реакция нәтиҗәсендә әле күптән түгел генә кабынып, дөрләп киткән милли тормышның сүрелеп калуы күренекле зыялыларның эзәрлекләнә башлавы һәм атаклы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең элекке шәүкәтен югалтуы аркылы метафорик төстә бирелә. Милли уяну, җанлану көннәренең символы булган шушы мәгариф учагы да сүнмәс, хан сарайлары, хан мәчетләре, Сөембикә манарасы язмышын кабатлап, «онытылмас, хәрабә хәленә калмас» микән, дигән борчу ярылып ята.

Язманың ахыры пессимизм һәм оптимизм антитезасы, өмет һәм өметсезлек диалектикасына корылган. Бер яктан: «Әйе, бүген караңгылык, томаналык белән күкрәк киереп көрәшкән бер буын, бер нәсел тәмам алҗыган бер хәлдә», диелсә, дәвамында: «Фәкать икенче якта аларның урынын алачак, алар башлаган эшләргә кабат җан өрәчәк әзерлекле, ялыкмас, дәртле-ялкынлы яңа бер буын, яңа бер нәсел килергә әзерләнә», – дип, киләчәккә өмет баглана. Халык бу сынаулардан да исән-имин үтеп, яңа көчләр белән алга атлар, диелә.

Хәлим Сабит бу язмасында бүгеннең «томаны» аркылы киләчәкне төсмерләгән күзәтүче, туган халкы язмышы өчен чын күңелдән борчылган, аның бәхетен, «җанлылык вакытын» хыялында йөрткән зыялы шәхес буларак күз алдына килеп баса.

## АЛТАЙЛАРГА ТАБА

Казанда.

Печән базары... Казан мөселманнарының сәүдә мәркәзе, алыш-биреш итү, очрашып-күрешү, фикер алмашу урыны... Шунда бер почмакта гына урнашкан «Болгар» номерларына таба юл тоткан чакта, Печән базары аша узмыйча, чаттагы Базар мәчете турында өелешкән елтыр күзле, симез Казан сәүдәгәрләре арасыннан үтмичә булмый. Шул чакта үткен пәке белән тап-такыр итеп кырылган башына «каракүл бүрек», өстенә кыйммәтле тун кигән Казан баеның резин тәгәрмәчле арбасы белән кибете янында торганын күрәсең... Бу бистәдәге сәүдә йортлары, магазиннар, складлар, кибетләр, кунакханәләр – һәркайсы Казанның төп халкы булган мөселманнар кулында. Моннан уңга, сулга һәм көньякка таба атласаң, магазиннары, матбагалары, көтебханәләре, чәйханәләре белән татар-мөселман мәхәлләләре җәйрәп ята. Төн ягына юл тотсаң, «Болак» күпереннән узып, шәһәргә соңрак өстәп корылган рус мәхәлләләренә барып чыгасың. Ул якларда Истанбулның Бәйугълы тирәләре шикелле гел чит-ятлар, кая карама руслар... Монда керә-керешкә руслык галәме, рус хәяты вә хәрәкәте күзгә бәрелә. Хакимият белән бергә күпчелек халык та шул тарафка килеп төпләнгән. Әмма ни генә булмасын, Казан, Русия төркләре күзаллавында, моннан 5 гасыр элеккеге шикелле үк, һаман да мөселман шәһәре булып кала бирә. Казанның гыйлем йортларында, дини мәдрәсәләрендә укып чыккан имамнар һәм галимнәр һәр чорда бу каланың бер гыйлем үзәге, дин мәркәзе икәнлеген әйтеп килгәннәр. 4–5 гасырлык заман тарих назарында кыска гына бер ара саналганга, Казанның элекке дәвере төрек-мөселман халкының хәтерендә тирән эзләрен саклап килә. Казанның җентекләп эшләнгән төпле язма тарихы булмаса да[1], шәһәргә барып чыккан яки аның исемен ишеткән төрек-мөселманның яше дә, карты да, укыганы да, укымаганы да күз уңында киң бер тарих сәхнәсе ачылганын күргән төсле була. Шул сәхнәдә һәрнәрсә чагыла, тамашачы алдына килеп баса.

[1] Бу мәкалә язылганнан соң, һәрнәрсәдәге кебек, бу мәсьәләдә дә үзгәрешләр булды: бүген шактый бай бер милли тарих көтебханәсенә ия булган Казан төрекләренең Казан тарихына караган әсәрләреннән кайберләре шулар: 1. Сөембикә тарихы (мулла Һади Атласи); 2. Казан тарихы (Нәҗип Хәлфин); 3. Татар тарихы (Г. Баттал); 4. Татар ханнары (мулла Касыйм Биккол); 5. Мөстәфад әл-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар (Шиһабетдин Мәрҗани); 6. Асар (Ризаэддин бин Фәхреддин); 7. Тәлфик әл-әхбар вә тәнких әл-асар (Мөхәммәд Морад әфәнде) 8. Казан тарихы (Гайнетдин Әхмәрев); 9. Мәдәният тарихыннан (Г. Гыйсмәти); 10. Тәварихы Болгария (Зәбири); 11. Рисаләи тәварихы Болгария... Монда исемнәре язылган һәм язылмаган бәгъзы затларның төрле мәҗмуга, рисалә, календарьларда һәм рус мәҗмуга вә китапларында чыккан әсәрләр һ. б. Моннан шуны күрәбез: бүген дикъкатьле бер күз өчен Казан тарихы – гыйльми сурәттә анализланып һәм эшләнеп җитмәгән булса да – халыкның рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерер дәрәҗәдә бар. Хәлим Сабит әфәнденең әйткәннәре «Мөстәфад әл-әхбар», «Асар», Гайнетдин әфәнденең «Казан тарихы» һәм берничә кечкенә «Тәварихы Болгария»ләрдән башка язма тарихлар булмаган чорга карый. Сәяхәтнамә шул елларда язылган. *Т.Й.*

Казанда күргән, очрашкан кешеләрнең һичбере бу шәһәргә аяк басар-басмас күңелемдә кайный башлаган сагыш вә хәсрәт тойгыларын арттырудан башкага ярамады.

Монда күргән кайбер хәлләр Казан тарихыннан бер вакыйганы искә төшерде: энесе Кече Мөхәммәд ханга җиңелгәч, Сарайдагы тәхетен ташлап китәргә мәҗбүр булган Олуг Мөхәммәд хан 4–5 мең яраны белән Идел буенда өлешчә Русия хакимияте астында булган бер җирдә, хөкемдарның рөхсәтен алып, тирмәләрен кора. Кыш җитүгә, суыктан һәм энесе яклы кешеләрнең эзәрлекләвеннән котылу өчен, Тау ягында (Җәбәлстан), Идел буйларында кардан-боздан ныгытмалар ясарга тотына. Заманында ханның химаясе ярдәмендә Мәскәү тәхетенә менеп утырган Өченче Василий элекке яклаучысының үтенечләренә колак салырга ашыкмый. Ахыр чиктә хан аңа шундый килешү тәкъдим итә: энесен җиңеп, Сарай тәхетен үзенә кайтара калган очракта, хараҗ (ясак) алуны туктатырга, моңарчы алганнарын да кире кайтарырга вәгъдә кыла, вәгъдәнең үтәлешен тәэмин итү өчен, үз улын әманәт итеп тапшырырга тели. Ләкин бу тәкъдименең дә бик кырыс вә тупас рәвештә кире кагылганын күргәч, хан тәмам өметсезлеккә төшә, күңеле боегып кала... Күп тә үтми каршысына 40 000 кешелек гаскәр килеп басканын абайлап ала... Шунда гына ул Алладан башка сыеныч, үз гайрәтеннән башка таяныч юклыгын тәмам төшенеп җитә. Башын сәҗдәгә куеп, Аллага ялвара. Үз гайрәт вә куәтенә мөрәҗәгать итә. Канлы сугыштан соң чирү тар-мар итеп ташлана. Шушы вакыйгадан соң Казан хөкүмәтенә нигез салына... Ләкин эш аның белән генә бетми, икенче бер бәрелештә кабат руслар җиңелеп, аларның хөкемдары әсир ителеп Мөхәммәд хан хозурына китерелә, ләкин ул тоткынны гафу итеп, иреккә җибәрә...

Казанның үткәне, тарихы никадәр буталчык, никадәр табышмаклы булса, бүгенге хәле дә шул нисбәттә яшерен, серле булып кала бирә. Моны үз исемемнән генә әйтәм, чөнки анда булып яткан хәлләрдән берни дә төшенә алмадым. Казанның алдынгы затлары, фикер ияләре, без яхшы дип инанган кешеләр ни өчен эзәрлекләнә, ни өчен күзәтү астында яши, иминчелектә түгелләр. Әллә аларның бер-бер кабахәтлеге, яманлыгы булып, мин генә күрмимме? Кабахәтлекләре, яманлыклары булса, ни өчен бөтен дөнья халкы аларны яхшы дип йөри, әллә алары да алданамы?

Менә шушы нәрсәләрнең төбенә мин төшеп җитә алмадым. Казан тарихыннан сакланып калган өзек-өзек мәгълүматлар арасында да шуңа охшаш хәлләр исемә төшә:

Якынча 920 (1514/1515) еллардан башлап Казан ханнары хәлифәлек йортына (Истанбул) ияргән Кырым ханнары тарафыннан җибәрелә башлаганга, Казан ханлыгы хәлифәләрнең мөмтаз вилаятьләре (эчке эшләрендә мөстәкыйль, тышкы эшләрдә үзәккә бәйле) рәтендә йөри, хотбәләрдә хәлифә өчен догалар укылып килә. Сафа Гәрәйне үз урынына калдырып Казан ханлыгыннан киткән Сахиб Гәрәй солтан Сөләйман Кануни тарафыннан Кырым ханы итеп

билгеләнгәч, Казанның хакимиятен дә үз кулында саклап кала. 956 елда Казан ханы Сафа Гәрәй вафат булгач, җияне Дәүләт Гәрәйне Казанга хан итеп куюны үтенеп, хәлифә хәзрәтләренә хат юллый. Фәкать солтан Сөләйман бер төркем интригантларның мәкерле сүзләренә ышанып, бичара Сахиб Гәрәй ханны үтертеп, аның урынына Дәүләт Гәрәйне Кырымга хан итеп куя, Казан ханлыгы онытылып, игътибардан читтә торып кала. Шушы вакыйгадан соң 33 ел үткәч, ягъни 961 дә булачак Казан ханлыгының инкыйразында бу хәлләрнең роле бик зур...

Солтан Сөләйман хәзрәтләре Сахиб Гәрәй ханны үтертү мәсьәләсе белән мәшгуль булган чакта асыл мәсьәләне – Казан ханлыгының яклаучысыз калганын чыннан да онытканмы яисә онытмаса да, аның язмышына артык әһәмият бирүне кирәк тапмаганмы?

Менә бу сорауларга да минем җавабым юк.

Заманында Казанга килгән саен иң тәүдә барып күргән бөек «Мәдрәсәи Мөхәммәдия»не бу юлы да онытмадым, бардым, күрдем. Ләкин күңелемнең борчуы арта гына төште. Монда да алга китеш күренми, хәлләр элеккедән дә кайтышрак иде. Берничә ел элек бу мәһабәт биналар гыйлем вә мәгарифкә сусаган шәкертләр белән тулып-ташып торса, бүген бушап, сүрелеп калган, борынгы абруен һәм гыйльми вәкарен җуйган төсле тоелды. Әллә күзләрем ялгыш күрәме, әйе, ялгыш булуын бик теләр идем, ләкин ни кызганыч, чынбарлык моның нәкъ киресен күрсәтә. Болай барса, күптән түгел генә бөтен Русия мөселманнары арасында бердәнбер диярлек югары гыйлем йорты булган бу мәдрәсә сүнү, сүрелүгә таба китәрме? Әллә ул да хан сарае, хан мәчете, Сөембикә манарасы кебек онытылып, ташландык хәрабә хәленә калырмы? Алар кебек үк бу мәдрәсәләр тарих чоңгылларында югалырмы?

Юк, мең мәртәбә юк, югалмас, күңелем шулай ди, иманым шул.

Әйе, бүген караңгылык, томаналык белән күкрәк киереп көрәшкән бер буын, бер нәсел тәмам алҗыган бер хәлдә. Фәкать икенче якта аларның урынын алачак, алар башлаган эшләргә кабат җан өрәчәк әзерлекле, ялыкмас, дәртле-ялкынлы яңа бер буын, яңа бер нәсел килергә әзерләнә. Моннан соңгы барча карашларыбыз да шулар ягына юнәлгән.

Тик монысы да минем хыялым гына булып калмаса ярар иде...

*Хәлим Сабит*

*Басмага әзерләде:*

***Вахитов Наил Ринат улы,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты аспиранты*

*К печати подготовил:*

***Вахитов Наиль Ринатович,***
*аспирант Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова АН РТ*

*bigey4052@gmail.com*